**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

3 август 2020 ел №283

Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан, Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Бишнә авыл җирлеге Советының «Бишнә авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Бердәм башкарма орган буларак яллаучы (сәяси партиядән тыш) булмаган оешмалар белән идарә итүдә яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә бушлай нигездә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 29 августындагы 120 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бишнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 августындагы 120 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 23 июлендәге 234 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**